ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

23.01.2023 | г. Иннополис | № 16

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2023 елның 1 февраленнән әлеге Карарга 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 7 793,48 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә мәет җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» Иннополис шәһәре Башкарма комитетының 28.01.2022 ел №05 карары 2023 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (httphttp://pravo.tatarstan.ru://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.Р. Хуззятов

Иннополис шәһәре Башкарма
комитетының
23.01.2023 16
карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1 | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 4 247,06 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 209,84 |
| 4 | Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 2 336,58 |
| Барлыгы | | 7 793,48 |

Иннополис шәһәре Башкарма комитетының
__23.01.2023 ____16
карарына

2 кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлегендә 2023 елның 1 февраленнән җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| № | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум.) |
|---|---|---|
| 1 | 1. Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Кәфенләү | 750,33 |
| 3 | Табут һәм җирләү өчен кирәк булган башка кирәк-яракларны бирү һәм китереп бирү | 3 496,73 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 209,84 |
| 5 | Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 2 336,58 |
| Барлыгы | | 7 793,48 |